ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 сентябрь 2021 ел

№ 6259

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функция башкаруның административ регламентын раслау турында» 2021 елның 8 июнендәге 3907 номерлы карары үз көчен югалтуын тану турында»

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законының 5 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган «Муниципаль хокукый актлар системасы турында» гы нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

Башкарма комитетның «Челнинские известия» газетасының 2021 елның 16 июнендәге 43 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2021 елның 16 июнендәге 43 санында басылып чыккан «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функция башкаруның административ регламентын раслау турында» 2021 елның 8 июнендәге 3907 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов